**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 елның декабреннән** **№ 21-111**

**«Аерым категориядәге гражданнарны җир кишәрлекләре өчен арендага түләүдән азат итү турында»**

Россия Федерациясе Җир кодексының 65 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Яңа Чишмә муниципаль районының норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Бер җир кишәрлегенә карата җирле бюджетка күчерелә торган сумманың 100% күләмендә җир кишәрлекләре өчен аренда түләвеннән түбәндәге категорияләрдәге гражданнарны азат итәргә:

1) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан Орденының тулы кавалерлары;

2) I һәм II инвалидлык төркеме инвалидлары, шулай ук составында I һәм II инвалидлык төркеме инвалидлары булган гаиләләр;

3) Балачак инвалидлары, шулай ук составында балачак инвалидлары булган гаиләләр;

4) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары;

5) «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-1 номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә) «Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган

Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәм «Теча» елгасына радиоактив калдыкларны ташлау турында» җитештерү берләшмәсендә һәм «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган физик затлар»;

6) махсус куркыныч бүлекчәләре составында атом-төш һәм термоатом-төш коралы сынауларында һәм хәрби объектларда атом-төш җайланмаларының аварияләрен бетерүдә турыдан-туры катнашкан физик затлар;

7) атом-төш җайланмаларының теләсә нинди төрләре белән бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр, шул исәптән атом-төш коралы һәм космик техниканы да кертеп, сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә инвалид булган физик затлар.

2. Гражданнарның аерым категорияләренең җир кишәрлекләре өчен аренда түләвен түләүдән азат итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- гражданның шәхси гаризасы;

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның җир кишәрлекләре өчен аренда түләвен түләүдән азат итү өчен нигез булуын раслаучы Россия Федерациясенең дәүләт органы тарафыннан бирелгән дәүләт үрнәгендәге документ.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2017 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**